РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» ноября 2025 ел г. Альметьевск № 2678

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы турында, Әлмәт муниципаль районы буенча 2025 елга торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның 14 мартындагы 564 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясының 4 өлеше нигезендә, «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгының 4.1 пунктына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «2025 елга торак урынны карап тоткан өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән түләү күләмнәрен мониторинглау нәтиҗәләре турында»2025 елның 09 сентябрендәге 04-04/125741 номерлы мөрәҗәгатенә нигезләнеп

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы турында, Әлмәт муниципаль районы буенча 2025 елга торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның 14 мартындагы 564 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2025 елның 01 августыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карарны 30 процент күләмендә билгеләргә».

заказ № 4553-940

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе И. Р. Фәсхетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Р. Фәсхетдинов